**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 август № 604

г. Казань

«Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын тормышка ашыру

Үз-үзләренә хезмәт күрсәтү мөмкинлекләрен тулысынча яки өлешчә югалткан өлкән яшьтәге гражданнарны озак вакыт тәрбияләү буенча стационарны алыштыра торган технологияләрне үстерү, аларның тормыш сыйфатын күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эхалыкны ш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 2017 елда «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» пилот проектын (алга таба – пилот проекты) Нигезләмә нигезендә тормышка ашырырга.

3. Пилот проектын тормышка ашыру максатында тәрбиягә алган гаилә төзегән һәм социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы түбәндәге гражданны (60 яшьтән өлкән ир-ат, 55 яшьтән өлкән хатын-кыз) тәрбияләүне гамәлгә ашыручы гражданга түбәндәге айлык акчалата түләү билгеләргә:

инвалид булмаган яки III төркем инвалиды булган – 4 мең сум күләмендә;

II төркем инвалиды булган – 6 мең сум күләмендә;

I төркем инвалиды булган – 8 мең сум күләмендә.

4. Пилот проектын тормышка ашыру 2017 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча күрсәтелгән максатларга каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

пилот проектын тормышка ашыруны методик тәэмин итү;

2018 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына пилот проектын тормышка ашыру йомгаклары буенча хисап һәм тәкъдимнәр тапшыру.

6. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 август, 604 нче
карары белән расланды

Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе һәм шартлары турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге юридик хокуклы гражданнар өчен тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

өлкән яшьтәге граждан – Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтә торган дәүләт учреждениесендә яшәүче өлкән яшьтәге юридик хокуклы граждан (60 яшьтән өлкән ир-ат, 55 яшьтән өлкән хатын-кыз) яки Татарстан Республикасы территориясендә торыр урыны булган һәм үз-үзенә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйль хәрәкәтләнү, төп яшәү ихтыяҗларын тәэмин итү сәләтен яисә мөмкинлеген тулысынча яки өлешчә югалту белән бәйле социаль яклау органнары тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге ялгыз яисә ялгыз яшәүче юридик хокуклы граждан;

тәрбиягә алган гаилә – социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданны өлкән яшьтәге граждан өчен тәрбиягә алган гаилә төзү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә өлкән яшьтәге граждан үз гаиләсендә яшәү чорында аны тәрбияләүне гамәлгә ашыру йөкләмәсен алган граждан гаиләсенә яшәргә урнаштыру формасы;

кандидат – Татарстан Республикасы территориясендә торыр урыны булган, өлкән яшьтәге гражданның аны тәрбияләүне гамәлгә ашыру йөкләмәсен үзенә алырга теләк белдергән гаилә әгъзасы (ире (хатыны), баласы, уллыкка (кызлыкка) алынган, тулысынча туган яки тулысынча туган булмаган (уртак әтисе яки әнисе булган) энесе яки сеңлесе, бертуганның улы яки кызы, оныгы яки аның ире (хатыны)) булмаган хезмәткә сәләтле яшьтәге балигъ булган юридик хокуклы граждан (60 яшькәчә ир-ат, 55 яшькәчә хатын-кыз);

ярдәмче – шартнамә нигезендә үзенә өлкән яшьтәге гражданны тәрбияләүне гамәлгә ашыру йөкләмәсе алган кандидат;

кандидат гаиләсе әгъзалары (ярдәмче гаиләсе әгъзалары) – кандидатныкы (ярдәмченеке) булган торак урында аның белән бергә яшәүче ире (хатыны), балалары һәм әти-әниләре, шулай ук башка туганнары, эшкә сәләтсез асрамалары һәм кандидат (ярдәмче) тарафыннан гаилә әгъзасы сыйфатында кергән бүтән гражданнар.

## 2. Тәрбиягә алган гаилә төзү тәртибе

2.1. Кандидат һәм өлкән яшьтәге граждан кандидатның яшәү урыны буенча гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәгенә яки Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә (алга таба – Комплекслы үзәк) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган форма буенча тәрбиягә алган гаилә төзү турында уртак язмача гариза (алга таба – гариза) белән мөрәҗәгать итәләр.

2.2. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) кандидат һәм өлкән яшьтәге гражданнын Россия Федерациясе гражданы паспортларының яки кандидат һәм өлкән яшьтәге гражданның шәхесен таныклый һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урынын раслый торган бүтән документларның законнар нигезендә таныкланган күчермәләре (төп нөсхәләрен күрсәтеп);

2) җирле үзидарә органыннан яисә күпфатирлы йорт белән идарәне гамәлгә ашыра торган торак-эксплуатация яки бүтән оешмадан кандидатның гаиләсе составы, кандидат яши торган урын булган торак урынның гомуми мәйданы зурлыгы турында белешмә;

3) кандидатның һәм аның белән яшәүче барлык гаилә әгъзаларының начар шешле авырулары һәм начар процесслар рецидивлары, хроник алкоголизм, наркомания, токсикомания, кискен йогышлы авырулары, туберкулезның актив формасы, авыр психик авырулары, венерик авырулары булмау турында дәүләт сәламәтлек саклау системасына керә торган оешмалар биргән белешмә;

4) кандидатның һәм аның белән яшәүче барлык гаилә әгъзаларының хөкемгә тартылмавы турында белешмә;

5) кандидат гаиләсенең барлык балигъ булган әгъзаларның, шул исәптән вакытлыча булмаучыларның, үзләре белән бергә аларның гаилә әгъзасы сыйфатында, кандидатның яшәү урыны адресы буенча яшәү урыны буенча яисә тору урыны буенча теркәлеп, өлкән яшьтәге граждан яшәвенә язмача ризалыклары һәм әгәр торак урын кандидатка социаль наем шартнамәсе буенча бирелсә, наемга бирүченең кандидат биләгән торак урынга өлкән яшьтәге гражданны кертүгә ризалыгы;

6) кандидат яши торган торак урынга милек яки файдалану хокукында ия булуның хокукый нигезләрен раслый торган документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре;

7) кандидат гаиләсенең гариза биргән айга кадәр соңгы алты календарь ае өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында» 2003 ел, 20 август, 512 нче карарын исәпкә алып исәпләнгән җан башына уртача кереме турында мәгълүматлар;

8) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 18 октябрь, 1075 нче карарын исәпкә алып исәпләнгән өлкән яшьтәге гражданның җан башына уртача кереме турында мәгълүматлар;

9) өлкән яшьтәге граждан өчен тәрбиягә алган гаилә төзелгән очракта аның стационар формада һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тартуы турында Министрлык раслаган форма буенча гаризасы;

10) кандидатның, кандидат белән бергә яшәүче барлык балигъ булган гаилә әгъзаларының, шул исәптән вакытлыча булмаучыларның, һәм өлкән яшьтәге гражданның Министрлык раслаган форма буенча язмача ризалыгы;

11) кандидатның Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә яраксыз гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга компенсация түләүләре турында» 2006 ел, 26 декабрь, 1455 нче Указы нигезендә билгеләнгән айлык компенсация түләвен алмавы турында өлкән яшьтәге гражданга пенсия түләү урыны буенча законнар нигезендә пенсия билгеләү һәм түләүне гамәлгә ашыра торган орган биргән белешмә;

12) өлкән яшьтәге гражданга социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы күчермәсе;

13) федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениесе биргән инвалидлык билгеләү турында, инвалидлык төркемен күрсәтеп (инвалид дип танылган өлкән яшьтәге гражданга карата), белешмәнең законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе;

14) кандидатның банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган, тиешле банк яки кредит оешмасында таныкланган шәхси счеты реквизитлары;

15) нотариуста яки Россия Федерациясе Граждан кодексының $185^1$ статьясында күрсәтелгән затлар тарафыннан таныкланган ышанычнамә күчермәсе һәм вәкилнең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе, аларның төп нөсхәләрен күрсәтеп (өлкән яшьтәге гражданның вәкиле мөрәҗәгать иткән очрата).

2.3. Документларның гаризага теркәлгән тиешле тәртиптә таныкланмаган күчермәләре төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм документларны кабул иткәндә Комплекслы үзәкнең вазыйфаи заты тарафыннан таныклана.

2.4. Комплекслы үзәкнең вазыйфаи заты гариза кергән көндә:

гаризаны һәм аңарга теркәлгән документларны, аларның дөрес формалаштырылуын, алардагы белешмәләрнең тулылыгын тикшерә;

гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, гаризаны кабул итә һәм терки.

Түбәндәгеләр гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган документларны тапшырмау;

гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшыру;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар, өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.

2.5. Гаризаны теркәгән көннән соң 30 эш көне эчендә Комплекслы үзәк түбәндәгеләрне башкара:

кандидат белән аның тормышының социаль-көнкүреш шартларын тикшерү көнен һәм вакытын килештерә, әлеге тикшерүне үткәрә һәм тикшерү актын төзи;

өлкән яшьтәге гражданның язмача ризалыгы белән кандидатка өлкән яшьтәге гражданның, шул исәптән Татарстан Республикасының халыкка социаль ярдәм күрсәтү учреждениесендә булган, сәламәтлеге торышы, керемнәре күләме һәм торак шартлары турында мәгълүмат бирә;

шартнамә төзү турында (төзүдән баш тарту турында) карар кабул итә, ул бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм Комплекслы үзәк директоры тарафыннан имзалана;

кабул ителгән карар турында (шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә – баш тартуның сәбәбен күрсәтеп) кандидатка язмача хәбәр җибәрә.

2.6. Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр түбәндәгеләр:

1) тәрбиягә алган гаилә төзү кандидатның яшәү урыны булган торак урынның гомуми мәйданы әлеге торак урында яшәүче, өлкән яшьтәге граждан яшәвен исәпкә алып, һәр затка исәпләгәндә гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә кую максатларында Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы билгеләгән торак урын мәйданының исәп нормасыннан кимрәк булуга китерсә;

2) кандидатның һәм аның гаилә әгъзаларының җан башына уртача кереме гариза биргән айга кадәр соңгы алты календарь ае өчен Татарстан Республикасында халыкның социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән булса.

2.7. Шартнамә төзү турында карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә Комплекслы үзәк Министрлык билгеләгән тәртиптә өлкән яшьтәге гражданны һәм кандидатны психологик әзерләү үткәрә.

### 3. Шартнамәне төзү һәм гамәлдән чыгару тәртибе

3.1. Тәрбиягә алган гаилә төзү максатларында Комплекслы үзәк, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Матди түләүләр үзәге), кандидат һәм өлкән яшьтәге граждан арасында дүртьяклы шартнамә төзелә.

Шартнамә Министрлык раслаган форма буенча 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булу вакытына төзелә.

3.2. Комплекслы үзәк шартнамәнең дүрт нөсхәсен имзалый һәм имза куяр өчен чиратлап кандидатка, өлкән яшьтәге гражданга, Матди түләүләр үзәгенә җибәрә.

Комплекслы үзәк тарафыннан шартнамә нөсхәләрен җибәрү вакыты – шартнамә төзү турында карар кабул ителгән, шартнамә якларының һәркайсыннан шартнамәнең имзаланган нөсхәләрен алган көннән соң бер эш көне.

Кандидат һәм өлкән яшьтәге граждан өчен шартнамәне карап чыгу һәм имзаланган нөсхәләрен Комплекслы үзәккә кайтару вакыты һәркайсына унар эш көне, Матди түләүләр үзәге өчен өч эш көне тәшкил итә.

3.3. Шартнамәдә тәрбиягә алган гаиләнең яшәү урыны күрсәтелә, өлкән яшьтәге гражданны тәрбияләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары, шартнамә якларының хокуклары һәм бурычлары, шул исәптән өлкән яшьтәге гражданны тәрбияләүне гамәлгә ашырган өчен ярдәмчегә айлык акчалата түләү күләме, аны түләү тәртибе һәм вакытлары (алга таба – айлык акчалата түләү), тәрбиягә алган гаилә бюджетын формалаштыру тәртибе һәм шартлары һәм аны тоту максатлары, шартнамәне гамәлдән чыгару өчен нигезләр, шартнамә шартларын үтәүне

тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе билгеләнә.

Шартнамәнең мәҗбүри шартларыннан берсе булып ярдәмче тарафыннан өлкән яшьтәге гражданны тәрбияләүне гамәлгә ашыру, аның төп яшәү ихтыяжларын тәэмин итү, медицина, психологик һәм юридик ярдәм күрсәтүгә ярдәм итү тора.

3.4. Тәрбиягә алган бер гаиләдә яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар саны ике кешедән артмаска тиеш.

3.5. Шартнамә нигезендә өлкән яшьтәге граждан ярдәмченең һәм аның гаилә әгъзаларының мөлкәтенә, ә ярдәмче һәм аның гаилә әгъзалары өлкән яшьтәге гражданның мөлкәтенә милек хокукы алмый.

Өлкән яшьтәге граждан ярдәмченең һәм аның гаилә әгъзаларының мөлкәте белән алар ризалыгы белән файдаланырга хокуклы.

Ярдәмченең һәм аның гаилә әгъзаларының өлкән яшьтәге граждан мөлкәте белән файдаланырга хокуклары юк, әгәр шартнамәдә бүтәне каралмаса.

3.6. Шартнамә нигезендә тәрбиягә алган гаилә бюджетына кертелә торган акча күләмен алып исәпләгәндә өлкән яшьтәге гражданның үзе карамагында кала торган акчасы суммасы аның айлык кеременең кимендә 25 процентын тәшкил итәргә тиеш.

3.7. Ярдәмче түбәндәге шартлар барлыкка килгәннән соң өч эш көне эчендә алар турында өлкән яшьтәге граждан белән бергә яшәү урыны буенча Комплекслы үзәккә хәбәр итәргә тиеш:

1) гаилә составы үзгәргән, бу чакта өлкән яшьтәге граждан белән бергә яшәү урыны булган торак урынның гомуми мәйданы әлеге торак урында яшәүче, өлкән яшьтәге граждан яшәвен исәпкә алып, һәр затка исәпләгәндә гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә кую максатларында Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы билгеләгән торак урын мәйданының исәп нормасыннан кимрәк булуга китерә;

2) ярдәмченең һәм (яки) аның белән яшәүче барлык гаилә әгъзаларының начар шешле авырулары һәм начар процесслар рецидивлары, хроник алкоголизм, наркомания, токсикомания, кискен йогышлы авырулары, туберкулезның актив формасы, авыр психик авырулары, венерик авырулары барлыкка килгән;

3) ярдәмче сак астына алынган, ярдәмчегә административ арест салынган, ярдәмче һәм аның гаилә әгъзалары җинаять өчен хөкем ителгән;

4) шартнамә нигезендә ярдәмче һәм өлкән яшьтәге граждан яши торган торак урынга ярдәмче милек яки файдалану хокукында ия булуга хокукый нигезләрен югалткан;

5) ярдәмченең һәм аның гаилә әгъзаларының җан башына уртача кереме соңгы алты календарь ае өчен Татарстан Республикасында халыкның социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән төшкән;

6) ярдәмчегә Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә яраксыз гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга компенсация түләүләре турында» 2006 ел, 26 декабрь, 1455 нче Указы нигезендә айлык компенсация түләве билгеләнгән.

3.8. Шартнамәнең гамәлдә булуы вакытыннан алда Россия Федерациясе законнарында, әлеге Нигезләмәдә һәм шартнамәдә каралган нигезләр буенча туктатыла.

3.9. Шартнамә өлкән яшьтәге граждан яки ярдәмче башлангычы белән

гамәлдән чыгарыларга мөмкин, бу хакта шартнамәне гамәлдән чыгарган көнгә кадәр кимендә 30 көн алдан Комплекслы үзәккә хәбәр итәргә кирәк.

3.10. Комплекслы үзәк түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә шартнамәне гамәлдән чыгара:

1) Комплекслы үзәк Министрлык билгеләгән тәртиптә үткәргән өлкән яшьтәге гражданның яшәү шартларын ай саен тикшерү нәтиҗәләре буенча өлкән яшьтәге гражданның ярдәмче яшәгән урында булмау факты билгеле булганда, өлкән яшьтәге гражданның туганнарында, медицина яки шифаханә-курорт оешмаларында булуыннан тыш;

2) ярдәмче шартнамә шартларын үтәмәгәндә;

3) өлкән яшьтәге граждан яки ярдәмче үлгәндә;

4) өлкән яшьтәге граждан яки ярдәмче Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәргә киткәндә;

5) ярдәмчегә Россия Федерациясе Президентының «Хезмәткә яраксыз гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы затларга компенсация түләүләре турында» 2006 ел, 26 декабрь, 1455 нче Указы нигезендә айлык компенсация түләве билгеләнгәндә;

6) өлкән яшьтәге граждан стационар формада һәм өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр алганда;

7) ярдәмче һәм өлкән яшьтәге граждан үзләре бергә яшәгән торак урынны югалтканда, шул исәптән янгын яки башка гадәттән тыш хәл белән бәйле;

8) өлкән яшьтәге гражданга карата ярдәмче һәм (яки) аның гаилә әгъзалары ягыннан физик, психологик яки сексуаль көчләү фактлары билгеле булганда;

9) ярдәмче сак астына алынган, ярдәмчегә административ арест салынган, ярдәмче яки аның гаилә әгъзалары җинаять өчен хөкем ителгәндә;

10) гаилә составы үзгәргәндә, бу чакта өлкән яшьтәге граждан белән бергә яшәү урыны булган торак урынның гомуми мәйданы әлеге торак урында яшәүче, өлкән яшьтәге граждан яшәвен исәпкә алып, һәр затка исәпләгәндә гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә кую максатларында Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы билгеләгән торак урын мәйданының исәп нормасыннан кимрәк булуга китерә;

11) ярдәмченең һәм (яки) аның белән яшәүче барлык гаилә әгъзаларының начар шешле авырулары һәм начар процесслар рецидивлары, хроник алкоголизм, наркомания, токсикомания, кискен йогышлы авырулары, туберкулезның актив формасы, авыр психик авырулары, венерик авырулары барлыкка килгәндә;

12) ярдәмче гаиләсенең балигъ булган әгъзасының (әгъзаларының), шул исәптән вакытлыча булмаучының (булмаучыларның), үзләре белән бергә аларның гаилә әгъзасы сыйфатында, ярдәмченең яшәү урыны адресы буенча яшәү урыны буенча яисә тору урыны буенча теркәлеп, өлкән яшьтәге граждан яшәвеннән язмача баш тартуы;

13) шартнамә нигезендә ярдәмче һәм өлкән яшьтәге граждан яши торган торак урынга ярдәмче милек яки файдалану хокукында ия булуга хокукый нигезләрен югалтканда;

14) ярдәмченең һәм аның гаилә әгъзаларының җан башына уртача кереме соңгы алты календарь ае өчен Татарстан Республикасында халыкның социаль-

демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән төшкәндә;

15) тәрбиягә алган гаилә төзү өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру факты билгеле булганда.

3.11. Комплекслы үзәк әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктында каралган шартлар билгеле булган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә ярдәмчегә һәм өлкән яшьтәге гражданга шартнамәне гамәлдән чыгару турында хәбәр итә.

Шартнамә түбәндәге очракларда гамәлдән чыккан дип санала:

әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктының 3, 4, 7 – 9, 15 пунктчаларында каралган очракларда – шартнамәне гамәлдән чыгару өчен нигезләр булган шартлар барлыкка килгән көндә;

әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктының 1, 2, 5, 6, 10 – 14 пунктчаларында каралган очракларда – шартнамәне гамәлдән чыгару турында хәбәр җибәрелгән көннән соң 10 көн узганнан соң.

3.12. Комплекслы үзәк шартнамәне гамәлдән чыгару нигезләренә бәйсез рәвештә өлкән яшьтәге гражданга киләчәктә социаль хезмәт күрсәтүне оештыру чараларын гамәлгә ашыра.

## 4. Айлык акчалата түләүне бирү тәртибе

4.1. Айлык түләүне бирү шартнамәнең гамәлдә булу вакытында өлкән яшьтәге гражданның тәрбиягә алган гаиләдә яшәгән көннәре санына пропорциональ башкарыла.

Өлкән яшьтәге гражданның туганнарында, тәрбиягә алган гаилә яши торган муниципаль районнан (шәһәр округыннан) читтә урнашкан медицина оешмаларында, шифаханә-курорт оешмаларында булу чорлары өлкән яшьтәге гражданның тәрбиягә алган гаиләдә яшәгән көннәре санына керми.

4.2. Комплекслы үзәк айлык акчалата түләү бирелә торган айдан соң килүче айның 5есенә кадәр Матди түләүләр үзәгенә үз эченә һәр ярдәмче хезмәт күрсәтә торган өлкән яшьтәге граждан саны, өлкән яшьтәге гражданның тәрбиягә алган гаиләдә яшәгән көннәре, күчерелергә тиешле сумма турында мәгълүматларны алган ярдәмчеләр реестрын (алга таба – Реестр) тапшыра.

Реестр формасын Министрлык раслый.

4.3. Матди түләүләр үзәге хисап аеннан соң килүче айның 8енә кадәр тапшырылган реестрлар нигезендә айлык акчалата түләүләр бирүгә чыгымнарны финанслау өчен җыелма заявка формалаштыра һәм аны Министрлыкка җибәрә.

4.4. Министрлык хисап аеннан соң килүче айның 10ысына кадәр айлык акчалата түләүләр бирүгә чыгымнарны финанслау өчен заявканы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә.

4.5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хисап аеннан соң килүче айның 15енә кадәр айлык акчалата түләүләр өчен кирәкле финанслауның чик күләмен (алга таба – финанслауның чик күләме) җиткерә.

4.6. Министрлык финанслауның чик күләме җиткерелгән көннән соң ике эш көне эчендә аны Матди түләүләр үзәгенә җиткерә.

4.7. Матди түләүләр үзәге шартнамә һәм реестр нигезендә хисап аеннан соң килүче айның 20есенә кадәр ярдәмче сайлавы буенча яки ярдәмченең үзе сайлаган банкта яки бүтән кредит оешмасында булган яки ачылган банк счетына яки сорап

алганга кадәр кертемгә айлык акчалата түләүне күчерә.

4.8. Шартнамәнең әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктындагы 1, 2 пунктчалар нигезендә вакытыннан алда гамәлдә булуын туктаткан очракта ярдәмчегә шартнамәдә каралган бурычлар аның тарафыннан үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән чорга айлык акчалата түләү бирелми.

4.9. Шартнамәнең гамәлдә булуы әлеге Нигезләмәдә каралган бүтән нигезләр буенча туктатылса, ярдәмчегә акчалата түләү шартнамәнең гамәлдә булуы туктатылган көнгә кадәр (ул көнне дә кертеп) өлкән яшьтәге граждан тәрбиягә алган гаиләдә фактта яшәгән көннәр өчен бирелә.

4.10. Ярдәмче үлгән көнгә алынмаган акчалата түләү аның гаилә әгъзаларына (өлкән яшьтәге гражданнан тыш) яки үлгән кешенең үлеме көнендә анда асрамада булган затка бирелә, алар Матди түләүләр үзәгенә ярдәмче үлгән көннән соң дүрт ай дәвамында аны түләүне таләп итеп мөрәҗәгать итсә.

4.11. Айлык акчалата түләү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.

4.12. Комплекслы үзәк, ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 25есенә кадәр Министрлык билгеләгән форма буенча айлык акчалата түләүләр бирү турында Министрлыкка хисап тапшыра.